ДИМ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 12** **16 ноябрь 2020 ел**

Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлегенең Екатериновка торак пунктында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә 7 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Дим-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсендәге 4 бүлекнең 4.4 пунктчасында билгеләп үтелгән, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 ноябрендәге 15 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Дим-Тамак авыл җирлеге башлыгы К А Р А Р  К А Б У Л  И Т Т Е:

1. 2020 елның 26 ноябренә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге, Екатериновка торак пунктында, Яшел урам, 13 санлы йорт каршында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештырырга.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2020 елның 13 ноябрендә кабул ителгән 4 санлы "Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлегенә керүче Екатериновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, балачактан инвалид булган, I һәм II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- Екатериновка бистәсендә вак таш җәелгән юлны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);» дигәнне "2021 елда үзара салым кертү Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Екатериновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән кешедән, балачак инвалидларыннан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына эшкә чакырылганнардан тыш, 2021 елда һәр балигъ булмаган кешедән 400 сум күләмендә акча кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Екатериновка торак пунктында Яшел урам буенча урнашкан юлга ком-вак таш катнашмасы белән юлны ремонтлау.» дип үзгәртергә сез ризамы?

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Дим-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Дим-Тамак авыл җирлеге
башлыгы Җ.А.Хөснетдинов